Национальная
библиотека
Республики Татарстан

# Һади Атласи – милләтебез горурлыгы

Методик-библиографик
ярдәмлек

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2026

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе

# Һади Атласи –
# милләтебез горурлыгы

Тарихчы, педагог, дин һәм җәмәгать эшлеклесе
Һади Атласиның (Һади Мифтахетдин улы Атласов;
1876–1938) тууына 150 ел тулуга багышланган
методик-библиографик ярдәмлек

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2026

**УДК 9(с 146)(092) Атласи Һ.01**
**ББК 63.1 (2Рос.Тат) – 81 Атласи Һ.я 1**
**Һ 16**

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият шурасы карары белән басыла

Төзүчесе Р.Р.Гаязова

Мөхәррире И.Г.Һадиев

**Һ 16** Һади Атласи – милләтебез горурлыгы: тарихчы, педагог, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Һади Атласиның (Һади Мифтахетдин улы Атласов; 1876–1938) тууына 150 ел тулуга багышланган методик-библиографик ярдәмлек / Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. Р.Р.Гаязова; мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2026. – 36 б.

Ярдәмлек Һади Атласиның үз әсәрләре һәм тарихи хезмәтләре, аның тормыш юлына һәм иҗатына багышланган әдәбият белән эшләү өчен китапханәчеләргә тәкъдим ителә. Җыентыкта искә алу кичәсе уздыру тәртибе, викторина үткәрү өчен сораулар, китапханәчегә киңәшләр һәм әдәбият исемлекләре бирелә.

**УДК 9(с 146)(092) Атласи Һ.01**
**ББК 63.1 (2Рос.Тат) – 81 Атласи Һ.я 1**

© Татарстан Республикасы
Милли китапханәсе, 2026;
© «Милли китап» нәшрияты, 2026.

## Кереш сүз

*«Үзенең кем икәнен белмәгән инсан*
*ничаклы хиссез исә, үзенең милләтенең*
*тарихын белмәгән инсан да*
*шул нисбәттә хиссездер».*
***Һади Атласи***

2026 елның 15 августында күренекле татар тарихчысы, педагог, җәмәгать эшлеклесе, галим, мәгърифәтче Һади Атласиның (Һади Мифтахетдин улы Атласов; 1876–1938) тууына 150 ел тула.

Татар халкының милләт горурлыгы Һади Атласи 1876 елның 15 августында Сембер губернасы Буа өязе Иске Чәке авылында (Татарстанның хәзерге Чүпрәле районы) мулла гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне әтисе мәктәбендә ала. Аннары Буаның танылган «Нурия» мәдрәсәсен, Оренбургның Каргалы бистәсендәге Гани бай Хөсәенов оештырган укытучылар әзерләүче семинариянe тәмамлый. 1898–1903 елларда Буа мәдрәсәсендә укыта, уку-укыту эшләрен яңартуга күп көч куя, яңа дәреслекләр төзү өстендә эшли, киң җәмәгать эшчәнлеге алып бара, беренче китапларын яза. 1902 елда аның «Гыйльме һәйәт» («Астрономия фәне») һәм «Тарихе табигый» («Табигать тарихы») хезмәтләре дөнья күрә.

1903 елның 29 маеннан Бөгелмә өязе Әлмәт авылы (хәзерге Әлмәт шәһәре) имам-хатыйбы, мәдрәсә мөдәррисе итеп билгеләнә. Мәдрәсә каршында кызлар мәктәбе ача.

Мөгаллимлеге белән беррәттән, Һади Атласи публицистик иҗатка да керешеп китә. Аның «Ахырзаман ишаны», «Идел буе», «Мәктәп һәм мулла» кебек беренче хезмәтләре басылып чыга.

1907 елда Һади Атласи Самара губернасыннан II Дәүләт Думасына депутат итеп сайлана, биредә ул «Мөселман хезмәт таифәсе» әгъзасы, «Дума» газетасын чыгаручыларның берсе була.

Мәгариф өлкәсендә патша хакимияте сәясәтен кискен тәнкыйтьләп, Һади Атласи 1906 елда «Яңа низам вә голямаларымыз» исемле публицистик хезмәтен бастыра, шуның өчен 1909 елда өч айга төрмәгә утыртыла. Ирекккә чыгарылгач, имам-мөдәррис вазифаларыннан баш тартырга мәҗбүр була. Полиция күзәтүе астында гаиләсе белән Бөгелмә шәһәрендә яши башлый.

Һади Атласи фән һәм әдәбият өлкәсендә зур эшчәнлек алып бара, гыйльми материаллар җыю, тарихи әдәбиятны өйрәнү өстендә эшли. Шул хезмәтләренең җимешләре буларак, 1911–1914 елларда бер-бер артлы аның «Себер тарихы», «Казан ханлыгы», «Сөен-бикә» исемле тарихи әсәрләре басылып чыга. 1913 елда ул Казан университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте»нең хакыйкый әгъзасы була. Бер үк вакытта «Йолдыз», «Вакыт», «Шура», «Мәктәп», «Аң» һ.б. вакытлы матбугат басмалары белән хезмәттәшлек итә.

1917 елгы Февраль революциясеннән соң милли демократик хәрәкәтнең актив әйдәүчесенә әверелә. Россиядә яшәүче төрки халыкларның милли-мәдәни мохтариятләрен оештыруны яклап чыга. Бөтенроссия мөселманнарының I һәм II корылтайларында катнаша, II корылтайда Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни автономиясен төзү нигезләрен әзерләүче комиссиягә әгъза итеп сайлана. 1917–1918 елларда Милләт мәҗлесе депутаты, төркичеләр фракциясе әгъзасы була.

Беренче бөтендөнья сугышы, 1917 елгы Февраль һәм Октябрь революцияләре, гражданнар сугышы елларында Һади Атласи гаиләсе белән Бөгелмә шәһәрендә яши. 1920 нче еллардагы ачлык вакытында Һ.Атласи Бөгелмәдә балалар йорты оештыруга булыша, өяз советында мәгариф мәсьәләләре белән шөгыльләнә. 1920 елның сентябрендә Совет хөкүмәте тарафыннан кулга алына һәм Баку шәһәрендәге Баилов төрмәсенә ябыла. ТАССР җитәкчелеге таләбе белән туган җиренә кайтарыла. Чистай шәһәрендә аклар контрразведкасына ярдәм итүдә гаепләп уздырылган мәхкәмә утырышында аклана һәм 1921 елның апрелендә ирекккә чыгарыла.

1921 елдан 1929 елга кадәр ул Бөгелмәдә икенче баскыч мәктәбендә тарих һәм немец теле укытучысы булып эшли.

Татар язуын гарәп графикасыннан латиницага күчерүгә каршы чыга. 1929 елда кабат кулга алына һәм Соловки лагерена озатыла. 1933 елда, сәламәтлеге начараю сәбәпле, лагерьдан азат ителә. 1934 елда Архангельскидан Бөгелмәгә кайтып ярты ел торгач, Һади Атласи гаиләсе белән Казанга күчеп килә.

1936 елда ул тагын кулга алына. Совет хөкүмәтенә каршы эш алып барган милләтчел контрреволюцион оешма төзүдә нахакка гаепләнеп, уйдырма яла нигезендә, бер төркем иптәшләре белән, 1938 елның 15 февралендә җәзалап үтерелә. Шулай итеп, татар халкының

мәшһүр улларыннан булган Һади Атласиның – биниһая зур шәхеснең – гомере ул чордагы күп зыялыларныкы төсле гаять аянычлы тәмамлана. 1958 елда ул аклана һәм реабилитацияләнә.

Һади Атласи мирасы зур кыенлыклар белән халыкка акрынлап кайтарыла башлый.

1996 елда Һади Атласи исемендәге иҗтимагый фонд булдырылды. Әлеге хәйрия фонды хәзерге көндә татар халкына, теленә, милләткә чын күңелдән хезмәт итүче милләтпәрвәрләребезне билгели. Алар галимнәр, әдипләр, җәмәгать эшлеклеләре, укытучылар арасыннан сайлап алына һәм Һади Атласи исемендәге «Мәгърифәтче» премиясенә яки «Фидакарь укытучы» премиясенә лаек була.

2003 елда Алсу Ханнан кызы Мөхәммәтдинова Һади Атласиның тормыш юлына, иҗатына багышланган кандидатлык диссертациясен яклады.

Язучы, тарихчы Фәүзия Бәйрәмованың олуг галим, милли азатлык көрәшчесе Һади Атласи турында «Соңгы туранчы» исемле китабы аның тууына 140 ел тулу уңаеннан басылып чыкты.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Һади Атласиның 150 еллыгын зурлап уздыру турында боерык кабул ителде.

Мәшһүр татар тарихчысы, галим, педагог һәм сәясәтче Мөхәммәтһади Мифтахетдин улы Атласи шәхесен һәм аның бай фәнни-иҗади мирасын укучыларга тагын да киңрәк таныту максатыннан аның юбилеен китапханәләрдә ел дәвамында зурлап билгеләп үтәргә, ярдәмлектә бирелгән материаллардан, әдәбият исемлегеннән файдаланып төрле чаралар: фәнни-гамәли конференцияләр, искә алу кичәләре, фикер алышулар, әңгәмәләр, айлыклар яки атналыклар, интеллектуаль уеннар һ.б. үткәрергә мөмкин. Интернет челтәрендә акцияләр уздыру, виртуаль китап күргәзмәсе, әдипнең китапларына презентацияләр, буктрейлерлар ясап урнаштыру да максатка ярашлы булыр.

Әлеге ярдәмлектә «Соңгы туранчы» дип аталган искә алу кичәсе үткәрү өчен әдәбият исемлеге, викторина үткәрү өчен сораулар һ.б. бирелә. Аларны оештыру өчен киңәшләр дә тәкъдим ителә.

Китапханәчеләр Һади Атласиның юбилей елын истә калырлык итеп уздыру өчен ярдәмлектә бирелгән материаллардан уңышлы файдаланырлар дип ышанып калабыз.

## Һади Атласи исемендәге премия лауреатлары исемлеге («Мәгърифәтче»-«Просветитель» премиясе)

*1996 елда Бөгелмә шәһәрендә Һади Атласи исемендәге иҗтимагый хәйрия фонды оештырыла. Татар фәнен һәм мәдәниятен үстерүгә зур өлеш керткән кешеләргә фонд тарафыннан ел саен тапшырыла торган премия булдырылган, ул, фонд рәсми рәвештә теркәлгәнче үк, 1994 елдан бирелә башлаган.*

**1994 ел** – Рәүф Ибраһимов – укытучы, педагогик хезмәт ветераны; Дания Аитова – Бөгелмә шәһәрендәге 2 нче лицейның татар теле укытучысы.

**1995 ел** – Айдар Хәлим – язучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе.

**1996 ел** – Равил Фәхретдинов – тарихчы-археолог, тарих фәннәре докторы, Идел буе Болгары, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы археологиясе өлкәсендә белгеч.

**1997 ел** – Миркасыйм Госманов – тарихчы галим, тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе академигы.

**1998 ел** – Гали Даутов – физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе әгъза-корреспонденты, физика терминнарының рус-татар сүзлеге авторларының берсе.

**1999 ел** – Фәрит Иделле – журналист, җәмәгать эшлеклесе.

**2000 ел** – премия бирелмәде.

**2001 ел** – Зәки Зәйнуллин – язучы, техник фәннәр докторы, инженер-атомчы, җәмәгать эшлеклесе.

**2002 ел** – Фәүзия Мәхмүтова – Бөгелмә муниципаль районы мәгариф идарәсе башлыгының милли мәгариф буенча урынбасары.

**2003 ел** – Разил Вәлиев – язучы, җәмәгать эшлеклесе.

**2004 ел** – Рөстәм Фәйзуллин (Акъегет) – шагыйрь, журналист.

**2005 ел** – Фәүзия Бәйрәмова – язучы, тарихчы, тарих фәннәре кандидаты, җәмәгать эшлеклесе; Зиннур Мансуров – шагыйрь, журналист, публицист.

**2006 ел** – Фазыл Вәлиәхмәтов – фотожурналист, җәмәгать эшлеклесе; Ринат Суфиев – язучы.

**2007 ел** – Дамир Асылов – журналист, җәмәгать эшлеклесе; Нур Әхмәдиев – шагыйрь.

**2008 ел** – Җәүдәт Сөләйманов – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы, «Сәләт» яшьләр үзәгенә һәм республика хәрәкәтенә нигез салучы.

**2009 ел** – Индус Таһиров – тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының беренче җитәкчесе.

**2010 ел** – Әзһәр Шакиров – Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты, җәмәгать эшлеклесе.

**2011 ел** – Туфан Миңнуллин – язучы, җәмәгать эшлеклесе.

**2012 ел** – Рабит Батулла – язучы, татар телендәге мәдәни-агарту телевизион һәм радио программалары авторы.

**2013 ел** – Мәхтүм Мостафин – «Бөгелмә авазы» газетасы мөхәррире; Роза Сәлманова – туган якны өйрәнүче (Әлмәт шәһәре).

**2014 ел** – Альберт Борһанов – тарих фәннәре кандидаты, җәмәгать эшлеклесе.

**2015 ел** – Радик Зәбиров – тарих фәннәре кандидаты, имам-хатыйп (Бөгелмә шәһәре).

**2016 ел** – Әнәс Ибраһимов – Бөгелмә һөнәри-педагогика көллияте директоры.

**2017 ел** – Хатыйп Миңнегулов – филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты профессоры.

**2018 ел** – Марат Туйкин – «Тамырлар»=«Корни» тарихи һәм мәдәни мирасны өйрәнү, саклап калу һәм үстерү фонды җитәкчесе (Әлмәт шәһәре).

**2019 ел** – Ринат Закиров – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе.

**2020 ел** – Җәүдәт Миңнуллин – тарих фәннәре кандидаты, галим; Фәрит Шәкүров – тарих фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты доценты.

**2021 ел** – Вахит Имамов – язучы, журналист, «Мәдәни җомга» республика газетасы мөхәррире.

**2022 ел** – Әнвәр Шәрипов – филология фәннәре докторы, Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты профессоры; Камәрия Хәмидуллина

– Ш. Мәрҗани исемендәге татар гимназиясе директоры, җәмәгать эшлеклесе.

**2023 ел** – Нәҗип Нәкъкаш (Исмәгыйлев) – рәссам-каллиграф, әдәбият белгече-текстолог, шамаилләр остасы.

**2024 ел** – Фауат Рәфыйков – «Җыен» татар телен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү хәйрия иҗтимагый фонды директоры.

**2025 ел** – Хөсәен Аймалетдинов – туган якны өйрәнүче, җәмәгать эшлеклесе.

**2026 ел** – Әскать Закиров – туган якны өйрәнүче, шәҗәрәләр төзү белгече (Бөгелмә шәһәре).

## Соңгы туранчы

*(Һади Атласины искә алу кичәсе)*

*Кичә Һади Атласиның хатларына, хатирәләренә, замандашларының истәлекләренә нигезләнеп төзелә. Кичәгә Һади Атласи турында материаллар туплап китап күргәзмәсе куярга, аның тормыш юлыннан төп вакыйгаларны тасвирлап ясалган кечкенә буклетлар ясап катнашучыларга таратырга киңәш итәбез.*

*Күрсәтелгән чыганакларда тупланган истәлекләрне, хатларны 2 укучы чиратлашып укыйлар. Шулай ук Һ.Атласиның «Себер тарихы», «Казан ханлыгы», «Сөен-бикә» әсәрләренән өзекләр укырга мөмкин.*

*Чараны башлар алдыннан Һади Атласиның биографиясе белән таныштыру өчен, Татар энциклопедиясе хезмәткәрләренең видеоязмасын* https://tatarica.org/tat/ razdely/nauka/personalii/atlasov-adi *сылтамасы белән тоташтырып, экранда күрсәтергә тәкъдим итәбез.*

## Файдалану өчен чыганаклар:


1. Атласи Һади. Сайланма әсәрләр: 2 томда / Һ. Атласи. – Казан: Җыен, 2009 –

Том 1: Себер тарихы. Сөен-бикә. Казан ханлыгы / [төз.: И. Гыймадиев, Р. Миңнуллин, Э. Сәлахова; фәнни мөх-ре һәм кереш сүз авт. М. Госманов; кереш сүз авт. А. Мөхәммәтдинова]. – 2009. – 559 б.

2. Атласи Һади. Сайланма әсәрләр: 2 томда / Һ. Атласи. – Казан: Җыен, 2009 –

Том 2: Мәкаләләр, хатлар, библиография / [кереш сүз авт. М. Госманов]. – 2010. – 351 б.

3. Һади Атласи: тарихи-документаль җыентык / [фәнни мөхәррир М. Госманов; төзүче-авт.: Р. Миңнуллин, А. Мөхәммәтдинова, И. Һадиев]. – Казан: Җыен, 2007. – 399 б.

4. Кайту = Возвращение: Һади Атласиның тууына 135 ел: 2011 елның 12 гыйнварында Чүпрәле районында күренекле татар тарихчысы, галим, мәгърифәтче Һади Атласига багышлап үткәрелгән чаралар турында / төз. Г. Рәхим. – Казан: Җыен, 2011. – 63 б.

5. Хисмәтуллина Н. Һади Атласи – милләтебез горурлыгы: [дәрес] / Н. Хисмәтуллина // Фән һәм мәктәп. – 2012. – № 2. – Б. 2–6.

6. Бәйрәмова Ф. Соңгы туранчы... (Һади Атласиның тууына 140 ел...) // Казан утлары. – Керү режимы: https://kazanutlary.ru/news/tarih/songy-turanchy

7. Һади Атласи // Безнең мирас. – Керү режимы: https://beznenmiras.ru/news/ochty-donya-chitlegennan/hadi-atlasi-1876-1938

8. Һади Атласов: тормыш юлы, эшчәнлеге. – Керү режимы: https://tat.nur.tatar/hadi-atlasov-tormysh-yuly-eshchenlege/

9. Заһидуллин Илдус. Татар патриоты – Һади Атласи // Татарстан. – Керү режимы: https://protatarstan.ru/news/history_tat/tatar-patrioti-hadi-atlasi

10. Һади Атласи. – Керү режимы: https://matbugat.ru/enc/atlasi-adi-888/

11. Һади Атласиның нәсел шәҗәрәсе буенча яңа мәгълүматлар // Шәһри Казан. – Керү режимы: https://shahrikazan.ru/news/əyter-syzem-bar/adi-atlasinyi-nsel-shrse-buencha-yaa-mglmatlar

12. Мухаметдинова А.Х. Хади Атласи как историк: автореф. дис. на соиск. уч. ст. канд. ист. наук. – Казань, 2003. – 23 с. – Режим доступа: https://dspace.kpfu.ru/xmlui/bitstream/handle/net/31846/ 734592.pdf

13. Шәймәрданов Р., Хуҗиәхмәтов Ә. Һади Атласи (1876–1938). – Керү режимы: https://gabdullatukay.ru/news/environment/r-shejmerdanov-e-hujiehmetov-hadi-atlasi-1876-1938

14. Таҗи Д. Һади Атласиның тәрҗемә хәленә кыскача бер караш. – Керү режимы: https://kitap.tatar.ru/tt/site/42317029a/pages/atlasi2/

15. Таипов Ш.Л. Һади Атласиның Әлмәт чоры: мәгърифәт реформасы, җәмәгать эшчәнлеге һәм тарихи хәтер. – Керү режимы: https://kitap.tatar.ru/tt/site/42317029a/pages/atlasi150/

16. Депутат, тарихчы һәм мөгаллим: Атласиның өзелгән язмышы. – Керү режимы: https://tatar-congress.org/yanalyklar/deputat-tarihchy-hem-mogallim-atlasinyn-ozelgen-yazmyshy/

**Викторина үткәрү өчен сораулар**

*(Түбәндә бирелгән сорауларны кулланып, укучылар арасында викторина үткәрергә, кроссворд төзеп чишәргә, интеллектуаль уеннар оештырырга мөмкин)*

1. Һади Атласи ничәнче елда һәм кайда туган?

*(1876 елның 15 августында, Сембер губернасы Буа өязе Иске Чәке авылында)*

2. Һади Атласи башлангыч белемне кайда алган?

*(Әтисе мәктәбендә)*

3. Һади Атласи язган тарихи әсәрләрнең исемнәрен санап чыгыгыз.

*(«Себер тарихы», «Казан ханлыгы», «Сөен-бикә»)*

4. Бөгелмә өязенең Иске Әлмәт авылында (хәзерге Әлмәт шәһәре) ул нинди вазифа биләгән?

*(Имам-мөдәррис)*

5. Һади Атласиның беренче публицистик хезмәтләрен атагыз.

*(«Ахырзаман ишаны», «Идел буе», «Мәктәп һәм мулла»)*

6. Һади Атласи кайсы елда Россия империясенең II чакырылыш Дәүләт думасына депутат итеп сайлана?

*(1907 елда)*

7. Һади Атласи нинди вакытлы матбугат басмалары белән хезмәттәшлек итә?

*(«Йолдыз», «Вакыт», «Шура», «Мәктәп», «Аң» һ.б.)*

8. Санкт-Петербургта нәшер ителгән нинди газетаны чыгаруда Һади Атласи актив катнаша?

*(«Дума»)*

9. Һади Атласи күрешеп яки хат аша аралашкан күренекле шәхесләрне санап чыгыгыз.

*(Бертуган Кәбир һәм Фазыл Туйкиннар, Мирсәет Солтангалиев, Галимҗан Нигъмәти, Ризаэтдин Фәхретдин, Фатих Кәрими, Габделбари Баттал, Габдрахман Шәфиев, Әхмәт-Зәки Вәлиди, Галимҗан Шәрәф, Газиз Гобәйдуллин, Садри Максуди һ.б.)*

10. Һади Атласи исемендәге премия ничәнче елдан бирелә башлый?

*(1994 елдан)*

11. «Белемле милләтләрнең үзләре вә яки балалары чәчкән гыйлемнең татлы җимешләрен ашаган заман, наданнарның балалары аталарының чәчкән наданлыкның ачы җимешләрен ашарга мәҗбүр булалар». – Әлеге юллар Һади Атласиның кайсы мәкаләсеннән алынган?

*(«Наданлык вә аның җимешләре» мәкаләсеннән)*

12. «Безнең мәктәпләребез» мәкаләсендә Һади Атласи «Наданлык – Алланың ачуы, белем исә – оҗмахның баскычыдыр», дип яза. Бу кемнең сүзләре?

*(Язучы һәм драматург Уильям Шекспир)*

13. «Ул чиктән тыш матур һәм сөйкемле вә шуның илә бәрабәр бик гакыллы бер кыз иде. Нугай кызлары арасында аңа охшаган кыз булмадыгы кеби, Казан һәм рус йортларында да аңа тиңдәш булырлык кыз юк иде. Ул – көн ягының иркен җәйләүләре илә аның мөлаем һавасында тәрбияләнеп үскән вә шуның илә бәрабәр тугмыштан матур булганлыгы өчен – дөньяның беренче сөйкемлесе иде». – Сүз кем турында бара һәм әлеге юллар Һади Атласиның кайсы әсәреннән алынган?

*(Сөембикә, «Сөен-бикә» әсәреннән)*

14. Һади Атласи нинди телләр белгән?

*(Рус, гарәп, фарсы, төрек, француз, алман)*

15. Һади Атласи үзенең хезмәтләрендә нәрсәгә каршы чыккан?

*(Рус булмаган халыкларны руслаштыруга каршы)*

16. 1930 нчы елларда Һади Атласиның кулга алынуларына нәрсә сәбәп була?

*(Совет хакимиятен тәнкыйтьләү һәм милли хәрәкәттә катнашу)*

17. Һади Атласи 1906 елда бастырган публицистик хезмәтенең исемен әйтегез.

*(«Яңа низам вә голямаларымыз»)*

18. Бөгелмә шәһәренең 14 нче номерлы татар гимназиясендә Һади Атласи исемендәге музейны кем оештырган?

*(Аның улы Угыз Атласи)*

19. 1921 елдан 1929 елга кадәр Һади Атласи Бөгелмәдәге икенче баскыч мәктәбендә нинди фәннәр укыткан?

*(Тарих, география)*

20. Һади Атласи турында фәнни-популяр китап авторын һәм исемен әйтегез.

*(Бәйрәмова Фәүзия, «Соңгы туранчы»)*

21. 1938 елның 15 февралендә Һади Атласи белән атып үтерелгән 8 татар зыялысының исемнәрен атагыз.

*(Һади Атласи (тарихчы) – 1876–1938; Гани Алтынбаев (укытучы) – 1902–1938; Касыйм Исхаков (имам) – 1890–1938; Фазыл Туйкин (язучы) – 1887–1938; Кәбир Туйкин (укытучы) – 1878–1938; Сабир Уразманов (укытучы) – 1892–1938; Барый Фаттахов (имам) – 1875–1938; Зәкәрия Фаттахов (хезмәткәр) – 1910–1938; Рәшит Яруллин (имам) – 1880–1938.*

## Һади Атласи турында кызыклы 10 факт*

Тарихчы, педагог, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче Һади Атласи – кызыклы, бай һәм гыйбрәтле тормыш юлы узган шәхес. Һади Атласи 1876 елда Сембер губернасы Буа өязенең Иске Чәке авылында туган. Башлангыч сабакны әтисе Мифтахетдин хәзрәттән алган. Киң карашлы галим булып җитешкән.

### 1. Милләтне уятучы

XX гасыр башында иң күренекле мөселман зыялыларының берсе буларак, татарларның сәяси үсешенә зур өлеш керткән һәм халык абруен казанган. Милли тарих, ялкынлы публицистика, алдынгы мәгърифәтнең башында нәкъ менә Һади Атласи тора. Узган гасыр башында милләтне уятучы буларак тарихта теркәлеп кала.

### 2. Педагог

Атаклы Буа мәдрәсәсендә укый. Аннары Оренбургның Каргалы бистәсендәге укытучылар әзерләүче семинариядә белем туплый. Остазлык эшчәнлеген Буа мәдрәсәсендә үк башлап җибәрә. Мәдрәсә белеме алган дин әһеле булуына карамастан, яңача фәнни мәктәпләр ачкан мөгаллим. 1921 еллардагы ачлык вакытында Һади Атласи Бөгелмәдә балалар йорты оештыруга булыша, өяз советында мәгариф мәсьәләләре белән шөгыльләнә. Бу чорда ул илнең төрле югары уку йортларында белем алучы студентларга матди булышлык күрсәткән Ярдәм комитетын җитәкли. Егерменче елларда Урта Азия шәһәрләре буйлап күп йөри, Россиядән китеп белем алуларын дәвам итсеннәр өчен, балаларны чит илләргә җибәрү белән дә шөгыльләнә. «Гыйльме һәйәт» («Астрономия»), «Тарихе табигый» («Табигать гыйльме тарихы») һ.б. дәреслекләр язган.

---

*https://magarif-uku.ru/news/news/hadi-atlasi-turynda-kyzykly-10-fakt Кыямова Мөршидә («Мәгариф» һәм «Гаилә һәм мәктәп» журналларының берләштерелгән порталы)

**3. Тарихчы**

Атласиның тарих темасына мәкаләләр язуы зур тарихи әсәрләр тудырган чорга туры килә, алар бергә иҗат ителә. «Бер милләтнең яшьләренә бабаларының борынгы хәлләре, аларның кылган эшләре белән сөйләгән сүзләре билгеле булса, ул милләт шиксез бар булып килә вә киләчәктә дә бар булачак!» – дип яза ул «Борынгы эш вә борынгы сүзләр» мәкаләсендә.

**4. Берничә тел белгән**

Туган теленнән тыш, рус, гарәп, фарсы, төрек һәм алман телләрен яхшы белгән. Күбесен мәдрәсәдән үк үзләштереп чыга. Үзе дини белем алган булса да, дөньяви фәннәр укытыла торган мәктәпләр ачкан. Бөгелмәдә кызлар мәктәбенә дә нигез сала.

**5. Үткен телле журналист**

Һади Атласиның барлык мәкаләләрендә дә диярлек дин һәм төркилек мәсьәләләре алгы урынга чыга, ул аларны милләтнең рухи нигезе дип саный. Әлмәттә яшәсә дә, Атласи үзенең үткен һәм төпле язмалары белән бөтен татар дөньясын «дер» селкетеп тота. Аның мәкаләләре «Йолдыз» (Казан), «Вакыт» (Оренбург) газеталарында, «Аң» (Казан), «Шура» (Оренбург), «Мәктәп» (Казан) журналларында һәм башка басмаларда дөнья күрә. Татар язуын латин графикасына (Яңалифкә) һәм кириллицага күчерүгә каршы чыккан.

**6. Сәясәтче**

Дәүләт Думасы депутаты. Мөстәкыйль фикерле диссидент. Үз карашларына нык инанган фикер иясе. Эсерлар фракциясендә торган. Соңрак Галимҗан Ибраһимовны да шул юнәлештәге карашлары өчен кискен тәнкыйтьләгәннәр.

## 7. Сталинга хат язган

Һади Атласовның 1935 елда язган хатыннан: «Мин, төрки-татар дөньясының карт җәмәгать һәм фән эшлеклесе, революционер, шушы өлкәдә узган гасырның соңгы елларыннан бирле эшлим. ...Мин – беренчеләрдән булып урыс самодержавиесенә һәм мөселман руханиларына каршы сугыш ачканнарның, беренче булып татар мәктәпләрендә география, табигать белеме, физика һәм астрономия кебек фәннәрне укыта башлаучыларның, азсанлы татар революционерларының берсе. Җәмәгать эшләрендә шактый дәрәҗәле урыннар биләдем. II Дәүләт думасы әгъзасы булдым һәм анда эсерлар фракциясендә тордым. Бу партиядә 1905 елдан 1918 елга кадәр әгъза булдым. Алардан китүемнең сәбәпләре – Брест килешүе һәм сугыш мәсьәләләре буенча социаль-революционерлар белән карашларыбызның туры килмәве...».

Сталинга язган хатында үзен гаиләсе белән Төркиягә җибәрергә рөхсәт сорый. Әмма максат-хыяллары чынга ашмый кала...

## 8. Гаиләсе

Хатыны Хөсникамал белән ике кыз һәм ике ул тәрбияләп үстерәләр: кызлары Сәлмә белән Сылу, уллары Габделбәр һәм Угыз Атласовлар. Хәзерге көндә дәвамчылары Казан каласында яши. Угыз әфәнде этисенең якты истәлеген кабаттан халыкка кайтаруда зур гамәлләр башкарган. Бөгелмәдә һәр ел саен Һади Атласины хөрмәт белән искә алалар.

## 9. Төрмәдә

Үз идеяләре һәм татар милләтенә тугры хезмәте аркасында 4 тапкыр төрмәгә утырталар. Соңгы тапкыр утыруында ирекка чыкмый. Һади Атласига нисбәтле байтак татар зыялылары җәбер-золымга тартыла. Араларында Атласи белән бөтенләй дә таныш булмаган, бер күрешмәгән кешеләр дә булган.

«Милләтчеләр», «Укытучылар», «Атласовчылар-Атласовщина» эше буларак җәмгыятькә таралган бу канлы вакыйгалар вакытында

Әлмәт-Бөгелмә-Шөгер төбәгеннән 107 татар кешесе кулга алынган, алар арасында 54 интеллигент-зыялы, 35 мулла, 18 «кулак-сәүдәгәр» булган. Башлыча остазлардан торган бу төркемнең башлыгы итеп Һади Атласи күрсәтелә. 1937 елның көзендә Казанда 24 кешегә суд карары чыгарыла: тугызы атып үтерелә, калганнары зинданнарга ябылып, күпләре шунда җан бирә...

## 10. Татарның соңгы туранчысы

Һади Атласи – ахырга хәтле татар халкының азатлыгы өчен көрәшкән, гомере буе төрки халыкларны берләштереп, бер бәйсез дәүләт төзү хыялы белән яшәгән, шуңа омтылган, шушы уй-гамәлләре өчен гомере белән түләгән соңгы туранчы... Һади Атласи үзенең төркиче-милләтче (пантюркист) булуын беркайчан да яшермәгән, төрки-татарлар бары тик бәйсез үз дәүләтләре булганда гына исән калачаклар дип матбугатка да язган, кулга алынгач, сорау алу вакытында да шуны кабатлаган, судта да соңгы сүзе итеп милләтнең азатлыгы турында сөйләгән.

## Библиография*

### Һади Атласиның хезмәтләре һәм әсәрләре

**1902**

Тарихе табигый. – Казан, 1902. – 31 б.

**1906**

Яңа низам вә голямаларымыз. – Оренбург, 1906. – 14 б.

Мәктәп вә мулла, яхуд Миңлебай суфиның тәгълиме вә программасы. – Казан: Мәгариф, 1906. – 16 б.

**1908**

Ислах нә димәктер? // Әл-Ислах. – 1908. – №19. – Б. 2–4.

**1909**

Дин саклау вә аңа ләякать // Шура. – 1909. – №22. – Б. 691–692; 1910. – №2. – Б. 38–39.

Урлар хакында тарихи мәгълүматлар // Шура. – 1909. – №14. – Б. 432–434.

**1910**

Бай һәм ярлы телләр, төрекчә югалган сүзләр // Шура. – 1910. – №7. – Б. 206–208.

Без һәм миссионерлар: (миссионерлар җәмгыятьләре) // Шура. – 1910. – №17. – Б. 527–529.

Безнең тәрәккый // Шура. – 1910. – №17. – Б. 745–748.

---

* Библиография. Һади Атласиның хезмәтләре һәм әсәрләре; Һади Атласига багышланган хезмәтләр һәм мәкаләләр (1902–2009) // Атласи Һ. Сайланма әсәрләр: 2 томда. Том II: мәкаләләр, хатлар, библиография. – Казан: Җыен, 2010. – Б.336–349.; Һади Атласи: Тарихи-документаль җыентык / төз.-авт. Р.Миңнуллин, А.Мөхәммәтдинова, И.Һадиев. – Казан: Җыен, 2007. – 400 б.

Әлеге исемлек тулыландырылып бирелә.

Безнең тел: Могтәбәр «Идел» газетасы илә Хәсән Гали әфәндегә җавап // Шура. – 1910. – №22. – Б. 684–688; №23. – Б. 711–712.

Бер төрк бикәченең үзенең угылына айган үгете / «Шура»ның тел ярышы. Мөрәттибе Ризаэтдин Фәхретдин // Вакыт (Оренбург), 1910. – Б. 70–72.

Борынгы эш вә борынгы сүзләр // Шура. – 1910. – №18. – Б. 557–559.

Йогышлы рәнҗү һәм татарлар // Шура. – 1910. – №16. – Б. 496–498.

Миссионерларны мактавым: (миссионерлар җәмгыятьләре) // Шура. – 1910. – №22. – Б. 676–678.

Наданлык вә аның җимешләре // Шура. – 1910. – №19. – Б. 604–605.

**1911**

Гарәпчәме, түгелме? // Шура. – 1911. – №3. – Б. 74–76.

Дәгъваи намус // Бәянелхак. – 1911. – №739 (20 март).

Ике дөнья // Бәянелхак. – 1911. – №771 (3 май).

Профессор Катанов илә мөсахәбә // Шура. – 1911. – №23. – Б. 711–713.

Саркыл шәһәре // Шура. – 1911. – №9. – Б. 273–275.

Себер тарихы. Беренче җөзьэ. – Казан: Өмид, 1911. – 177 б.

Тәнкыйтьне тәнкыйть // Шура. – 1911. – №15. – Б. 69–70.

Шәйхелислам хәзрәт [Ш.Хәмиди вафаты турында] // Йолдыз. – 1911. – №692.

**1912**

Ачлык вә мөселманнар // Шура. – 1912. – №1. – Б. 15–16.

**1913**

Әрәм акчалар: Мәктәпләр хисабына бүләк ителгән акчаларның дөрес тотылмавы // Мәктәп. – 1913. – №12. – Б. 292–294.

Башкалар ничек укыйлар?: Белем бирүгә тотылган акча һәм мәктәпләрдә укучылар саны буенча төрле илләрне чагыштыру // Мәктәп. – 1913. – №5. – Б. 123–125.

Башкортлар хакында берәр сүз // Шура. – 1913. – №9. – Б. 261–263; №10. – Б. 297–299.

Безнең мәктәпләремез: Мәктәпнең максаты. Төрле халыкларны белем бирү эшләре буенча чагыштыру. Тормышка якын мәктәп мәсьәләсе // Мәктәп. –1913. – №1. – Б. 19–20.

Гани бай кем иде? // Шәрәф Б. Гани бай. – Оренбург, 1913. – Б. 230–246.

Гимназияме, приютмы? // Аң. – 1913. – №6. – Б. 104–106.

Ерткычлык түгелме?: Мәктәп-мәдрәсәләрдә физик көч кулланып, «таяк» белән укыту турында // Мәктәп. – 1913. – №6. – Б. 157–160.

Мәктәпләремездә игътикад һәм гыйльме халь китаплары: [дини китапларга тәнкыйть, мәктәп-мәдрәсәләр өчен тормышка якынайтылган дини дәреслекләр язу мәсьәләсе] // Мәктәп. – 1913. – №9. – Б. 222–224.

Земство вә безнең мәктәпләр: [мөселманнарның земство эшләрендә катнашмаулары һәм шунлыктан мәгариф эшләренә игътибар бирелмәү] // Мәктәп. – 1913. – №15. – Б. 361–363.

**1914**

Америка көтепханәләре: Кайбер китапханәләр турында мәгълүмат: тарихлары, матди хәлләре һ.б. // Мәктәп. – 1914. – №7. – Б.161–163.

Башкорт җирләре // Йолдыз. – 1914. – №1163. – Б. 1.

Игенчелек һәм аның тәрәккыяте // Йолдыз.– 1914.– №1144. – Б. 1.

Казан ханлыгы.– Казан: «Өмет» матбагасы, 1914.–1 җилд.– 336 б.

Сөен-бикә: тарихи хикәя. – Казан: Типолитография «Өмид», 1914. – 62 б.

**1915**

Шиһаб хәзрәт кем иде? // Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә

нәшер ителде. – Казан: нашире Салих бине Сабит Гобәйдуллин; Мәгариф, 1915. – Б. 459–467.

**1920**

Казан ханлыгы. Икенче басма. – Казан, 1920. – 344 б.

**1991**

Сөембикә: романнан өзек / Һади Атласи // Шәһри Казан. – 1991. – 3–22 август.

Тарихчы язмалары: «Казан ханлыгы» һәм «Сөен бикә» исемле тарихи әсәрләрдән өзек / язмаларны С.Алишев әзерләде // Социалистик Татарстан. – 1991. – 2 август.

**1992**

Себер тарихы. Сөен-бикә. Казан ханлыгы: Тарихи әсәрләр / төз., кереш сүз, искәрмәләр һәм белешмәләр авторы С.Алишев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 448 б.

Сөен-бикә: әсәрдән өзек / Һади Атласи // Аҗаган. – 1992. – №1. – Б. 8.

Сөен-бикә: әсәрдән өзек / Һади Атласи // Кызыл Таң. – Уфа. – 1992. – 16–18 июль.

Сөен-бикә / редкол.: Р.Вәлиев, М.Госманов, Ә.Кәримуллин, Р.Сираҗиев. – Казан: «Җыен» фонды, 1992. (Репринт басма: Атласов Һ. Сөен-бикә. – Казан: Типолитография «Өмид», 1914. – 62 б). – 72 б.

**1993**

Себер тарихы. Сөенбикә. Казан ханлыгы: тарихи әсәрләр / Һади Атласи / төз., кереш сүз, иск. һ. белешмәләр авт. С.Х.Алишев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 447 б. (Татар тарихы китапханәсе).

**1994**

Ядкәр хан // Татар тарихы: онытылмас сәхифәләр: Татарстан Мәгариф министрлыгы тарафыннан тарих дәресләренә өстәмә әдәбият буларак тәкъдим ителә / төз. С.Х.Алишев һ.б. – Казан: Мәгариф, 1994. – Б. 161–204. – («Мәгариф» китапханәсе).

**1995**

Чыңгыз хан: Алтын Урда тарихыннан // Мирас. – 1995. – №7–8. – Б. 142–143.

**1996**

Наданлык һәм аның җимешләре: әдәби мирас: (мәкалә иске телдә төп нөсхәдә бирелә) // Бөгелмә авазы. – 1996. – 21 ноябрь.

Сөен-бикә: әсәрдән өзек / Һади Атласи // Сөембикә. – 1996. – №8. – Б. 38–39.

Яңа низам вә голямаларыбыз // Татарстан. – 1996. – №11. – Б. 22–25; Казан утлары. – 1996. – №12. – Б. 58–160.

**1998**

Сөен-бикә: әсәрдән өзек / Һади Атласи // Мирас. – 1998. – №10. – Б. 87–111.

**2005**

Казан ханлыгы. – Казан: Мәгариф, 2005. – 247 б.

История Сибири: неизвестное о покорении края / Хади Атласи (Хади Мифтахутдинович Атласов); перевод с татарского языка А. Бадюгиной; автор предисловия И.К.Загидуллин; художник Р.Г.Шамсутдинов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. – 95 с.

**2009**

Сайланма әсәрләр: 2 томда. I т.: Себер тарихы. Сөен-бикә. Казан ханлыгы. – Казан: Җыен, 2009. – 560 б.

**2010**

Сайланма әсәрләр: 2 томда. II т.: Мәкаләләр, хатлар, библиография. – Казан: Җыен, 2010. – 352 б.

**2014**

Сөенбикәне сагыну: [тарихи мирас] // Безнең мирас. – 2014. – № 10. – Б. 18–19.

**2016**

Казан ханлыгының соңгы көннәре: [Казан тарихы] // Мәдәни җомга. – 2016. – 11 ноябрь (№44). – Б. 11.

Һади Атласиның «Йолдыз» газетасында басылган ике мәкаләсе: [«Безнең байлар» мәкаләләре 1910 һәм 1914 елларда басылган. Текст һәм искәрмәләрне басмага Л.Гобәйдуллин әзерләде ] // Безнең мирас. – 2016. – №8. – Б. 13–16.

**2017**

Тел турында уйланулар: [галимнең 1910 елда «Шура» журналында басылган «Бай һәм ярлы телләр, югалган төркичә сүзләр» мәкаләсе гарәп графикасыннан күчереп бирелә; кереш сүзне А.Рәхимова язган] // Безнең мирас. – 2017. – №5. – Б. 98–103.

**2021**

Сөем-бикә: [әсәрдән өзек] // Сөембикә. – 2021. – №10. – Б. 26–29.

**2023**

Яңа низам һәм голәмәбез: [Һади Атласиның 1906 елда «Вакыт» газетасының 84 нче санында чыккан милләт һәм дин турында мәкаләсе] / Һ.Атласи // Мәдәни җомга. – 2023. – 25 август (№ 33). – Б. 2, 4.

## Һади Атласига багышланган хезмәтләр һәм мәкаләләр

**1907**

Госмани Хәйрулла. Фөрьяд [Думадагы татар депутатлары, шул исәптән Һ.Атласи турында] // Дөнья вә мәгыйшәт. – 1907. – №12. – Б. 191–192.

**1913**

Һади әфәнде Атласов // Заман календаре. – Казан, 1913. – Б. 58.

**1914**

Алтай. Сөенбикә // Йолдыз. – 1914. – №1236.

Вәлиди З. Сөенбикә: Һади Атласи әсәре [Казан, «Өмид» матбагасы, 1914. Китаплар һәм аларга тәнкыйть] // Сөембикә. – 1914. – №4. – Б. 7–11; №5. – Б. 5–6.

**1916**

Бартольд В.В. Труды популярного татарского публициста Гади (Хади) Атласова, посвящённые истории Сибири и Казани // Записки Восточного отделения Русского археологического общества. – 1916. – Т. 23. – Вып. 3–4. – С. 421–422.

**1923**

Валиди Дж. Очерки по истории образованности и литературы татар. – М., П., 1923. – С. 146.

**1926**

Губайдуллин Г.С. Развитие исторической литературы у тюрко-татарских народов // Первый Всесоюзный тюркологический съезд: стенографический отчет. – Баку, 1926. – С. 48.

**1981**

Город счастливой судьбы: 200 лет Бугульме (исторический очерк). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1981. – С. 78.

**1986**

Абдуллин Я. Һади Атласи турында / Я. Абдуллин, М.Госманов, И.Таһиров // Казан утлары. – 1986. – №11. – Б. 172–176.

**1989**

Абдуллин Я. Правда о Хади Атласи / Я.Абдуллин, М.Усманов, И.Тагиров // Наука. – 1989. – 24 июля.

**1990**

Алишев С. Тарихчының фаҗигале язмышы // Социалистик Татарстан. – 1990. – 5 август.

Гарифуллин Д. Һади Атласов: репрессияләнгән мәгърифәтче язмышы // Әлмәт таңнары. – 1990. – 16 июнь.

Госманов М. Тарихчы һәм җәмәгать эшлеклесе Һади Атласи // Госманов М. Үткәннән киләчәккә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – Б. 71–80.

Кадыров Р. Трудная судьба просветителя [учёного, историка Х.Атласова] // Ленинское знамя. – 1990. – 24 ноября; Ленин байрагы. – 30 ноябрь.

Султанбеков Б. «Дело» Хади Атласова: в контексте политической атмосферы 30-х годов // Советская Татария. – 1990. – 11 февраля.

**1991**

Атласов У. Тарихны тарихчылар язсын // Бөгелмә авазы. – 1991. – 13 май.

Атласов У. Ачы хакыйкать: Һ.Атласиның тууына 115 ел тулу уңаеннан // Бөгелмә авазы. – 1991. – 27 август.

Гарифуллин Д. Һади Атласов // Бөгелмә авазы. – 1991. – 29 ноябрь.

Гарифуллин Д. Һади бабай фәлсәфәсе: шигырь // Социалистик Татарстан. – 1991. – 9 август.

Кәримуллин Ә. Һади Атласи һәм аның «Сөен-бикә»се // Шәһри Казан. – 1991. – 3 август.

Мостафин М. Исемнәре кайтсын халыкка: Һ.Атласи, Г.Сәгъди, А.Таһиров һ.б. турында // Бөгелмә авазы. – 1991. – 9 август.

Султанбеков Б. «Дело» Хади Атласова: в контексте политической атмосферы 30-х годов // Султанбеков Б. Первая жертва Генсека. Мирсаид Султан-Галиев: Судьба. Люди. Время. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. – С. 72–99.

Хаҗиев В. Педагог һәм тарихчы Һади Атласов // Мәгариф. – 1991. – №10. – Б. 54–56.

**1992**

Алишев С. Татар тарихчысы Һади Атласи // Себер тарихы. Сөен-бикә. Казан ханлыгы: Тарихи әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – Б. 3–15.

Гарифуллин Д. «Мин изелгән халыкның улы...» // Татарстан хәбәрләре. – 1992. – 18 сентябрь.

Госманов М. Авыр тарихның моңлы кайтавазы // Атласов Һ. Сөен-бикә.– Казан: «Җыен» фонды, 1992. (Репринт басма: Атласов Һ. Сөен-бикә.– Казан: Типолитография «Өмид», 1914. – 62 б.). – Б. 64–71.

Үтәбай-Кәрими Р. Тарих чагылышы // Нур. – 1992. – 1 август.

**1993**

Литвин А. «Милләтчеләр» эше (Һ.Атласи турында архивлар ни сөйли?) // Казан утлары. – 1993. – №4. – Б. 155–166.

Литвин А. «Милләтчеләр» эше. (Һ.Атласи турында) // Татар иле. – 1993. – №12–13. – Б. 13.

Литвин А. «Милләтчеләр» эше яки Һ.Атласи турында архивлар ни сөйли? // Бөгелмә авазы. – 1993. – 24 июнь – 12 август.

Литвин А. Операция «Националисты» // Литвин А.Л. Запрет на жизнь. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. – С. 42–60.

**1994**

Алишев С. Тарихыбыз язылган. Укый белергә генә кирәк // Татарстан яшьләре. – 1994. – 8 февраль.

Курат Әкъдәс Нигъмәти. Казан төрекләренең танылган тарихчы һәм милләтчеләреннән Һади Атласи // Аргамак. – 1994. – №11. – Б. 91–97.

Мостафин М. Һади Атласи музее булырмы? // Шәһри Казан. – 1994. – 14 октябрь.

Мөхәммәдиев Ә. Кире кайтарылган хәзинә // Ватаным Татарстан. – 1994. – 18 март.

Солтанбәков Б. Һади Атласи кисәтә // Солтанбәков Б. Тарих серләре ачыла. – Казан, 1994. – Б. 13–23. («Казан» журналы китапханәсе. – №9–10.)

**1995**

Хаҗиев В. Һади Атласи мәктәбе // Мирас. – 1995. – №7–8. – Б. 108–113.

**1996**

Алишев С. Ут эчендә калган күргәчен // Татарстан. – 1996. – №11. – Б. 20–21.

Алишев С. Ут эчендә калган күргәчен кебек / С.Алишев, Р.Галләмов // Казан утлары. – 1996. – №12. – Б. 157–158.

Асылов Д. Татарның бер каһарманы // Ватаным Татарстан. – 1996. – 10 сентябрь.

Асылов Д. Фидаи җан: педагог, җәмәгать эшлеклесе, тарихчы-галим Һ.Атласи турында // Әлмәт таңнары. – 1996. – 26 сентябрь; 17 октябрь.

Галиев Ә. Музей ачылды (мәгърифәтче Һ.Атласига багышлана) / Галиев Ә., Булатов М. // Бөгелмә авазы. – 1996. – 7 декабрь.

Каюмова Ә. Ничәмә дистә еллар үтсә дә... (Һ.Атласиның тууына 120 ел тулуга карата) // Бөгелмә авазы. – 1996. – 7 декабрь.

Кәримуллин Ә. Һади Атласи һәм аның «Сөен-бикә»се // Кәримуллин Ә.Г. Язмыш, язмыш... – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – Б. 126–128.

Хаҗиев В. Гасырның ул хөр токтыны иде: (танылган җәмәгать эшлеклесе Һади Атласиның тууына 120 ел) // Мәдәни җомга. – 1996. – №32. – 9 август. – Б. 8.

**1997**

Асылов Д. Мәйдан тотучыларның берсе: шәхес культы корбаны Һ.Атласи // Татарстан. – 1997. – №1. – Б. 66–73.

XX йөз башы татар тәгълим-тәрбия журналларының библиографик күрсәткече («Тәрбия әтфаль», «Тәрбия», «Мәктәп», «Мөгаллим») / төз.: Р.Мәрданов, И.Галләмев. – Казан: Милли китап, 1997. – Б. 1–22.

Миңнуллин Р. Һади Атласи // Гасырлар авазы=Эхо веков. – 1997. – №1–2. – Б. 246–248.

**1998**

Атласов Хади Мифтахутдинович (Хади Атласи) (1876–1938) // Татарский энциклопедический словарь. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1998. – С. 46.

«Атласова» дело // Татарский энциклопедический словарь. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1998. – С. 46–47.

Зәйнетдинов М. Тормышка ашасы хыял: Һ.Атласи турында // Бөгелмә авазы. – 1998. – 4 июнь.

**1999**

Абдуллин Я. Һади Атласи – галим һәм җәмәгать эшлеклесе / Я.Абдуллин, М.Госманов, И.Таһиров // Абдуллин Я. Милләт язмышы: уйланулар. – Казан: Фән, 1999. – Б. 103–111.

Усманова Д. Мусульманская фракция и проблемы «свободы совести» в Государственной Думе России (1906–1917). – Казань: Мастер-Лайн, 1999. – С. 56, 67, 129, 141.

**2000**

Даутов И. Һади Атласи // Кызыл Таң (Уфа). – 2000. – 13 гыйнвар.

Каюмова Ә. Үткән юллар, үткән еллар // Мирас. – 2000. – №6. – Б. 73–74.

Мөгыйнев Р. «Әлмәт эше»нә тәнкыйди бәя / Энгель Нигъмәтуллин тәрҗ. // Мирас. – 2000. – №11. – Б. 77–86.

**2002**

Атласов Хади (Мухамматхади) Мифтахутдинович (Хади Атласи) (15.8.1876, д. Ниж. Чеке Буинского у. Симбирской губ. – 15.2.1938, Казань) // Татарская энциклопедия: в 5 т. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2002. – Т. 1: А–В. – С. 222–223.

«Атласов» эше // Татар энциклопедия сүзлеге. – Казан: ТР ФА Татар энциклопедиясе институты, 2002. – Б. 50.

Атласов Һади Мифтахетдин улы (Һади Атласи) (1876–1938) // Татар энциклопедия сүзлеге. – Казан: ТР ФА Татар энциклопедиясе институты, 2002. – Б. 50.

Хабутдинов А. Хади Атласи: уроки прошлого // Идель. – 2002. – №1. – С. 62.

Шакуров Ф. Развитие исторических знаний у татар до февраля 1917 года. – Казань: изд-во Казан. университета, 2002. – С. 41–43.

Һади Атласи истәлегенә // Мәгариф. – 2002. – №6. – Б. 75.

**2003**

Мухаметдинова А. Хади Атласи как историк: автореферат диссертации на соискание ученой степени кандидата исторических наук: 07.00.02. – Отечественная история / Алсу Ханнановна Мухаметдинова. – Казань, 2003. – 22 с. – На правах рукописи.

**2004**

Мухаметдинова А. Хади Атласи: общественный деятель и историк / Алсу Ханнановна Мухаметдинова; научный редактор и автор предисловия И. Р. Тагиров. – Казань: изд-во Казан. университета, 2004. – 128 с.

Султанбеков Б. Хади Атласов предупреждает // Татарские края. – 2004. – №37. – С. 6.

**2005**

Асылов Д. Һади Атласи // Бөгелмә авазы.– 2005.– 26 август.– Б. 4.

**2006**

Асылов Д. Инсанны инсан иткән тарихтыр: Һади Атласиның мирасын өйрәнү, Татарстанның Бөгелмә төбәгендә аның 130 еллыгына багышланган чаралар турында // Мәдәни җомга. – 2006. – 10 ноябрь (№44). – Б. 15.

Хабутдинов А. Без дня вчерашнего нет дня сегодняшнего: о двух татарских политиках и историках, участниках III Всероссийского мусульманского съезда (1906 г.) в Нижнем Новгороде Юсуфе Акчуре и Хади Атласи // Медина. Аль-Ислам (Нижний Новгород). – 2006. – Октябрь (№9). – С. 13.

**2007**

Һади Атласи: тарихи-документаль җыентык / төз.-авт.: Р.Миңнуллин, А.Мөхәммәтдинова, И.Һадиев. – Казан: Җыен, 2007. – 400 б.

Һади Атласи исемендәге музей-китапханә йорты / [төз. Ф. Вәлиәхмәт]. – [Казан]: Татнефть, 2007. – 23 б.

**2008**

Асылов Д. Атласи рухын яд итү // Мәдәни җомга. – 2008. – 7 март. – Б.11.

Асылов Д. Ул бүген дә байракчыбыз // Мәдәни җомга. – 2008. – 24 июнь. – Б. 16.

Харисова Л. Атласи и его педагогический подвиг во имя народа // Харисова Л. Педагогический потенциал ислама. – М.: ООО «ТИД Русское слово – РС», 2008. – С. 114–115.

**2009**

Асылов Д. Онытма син үткәннәрне // Мәдәни җомга. – 2009. – 3 апрель. – Б. 16.

Һади Атласи – тарихчы һәм җәмәгать эшлеклесе // Историко-культурное наследие=Тарихи мәдәни мирас. – 2009. – апрель. – Б. 10.

**2011**

Гази Н. Атласи киләчәккә атлый: [тарихчы-галим, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Һади Атласиның тууына 135 ел тулу уңаеннан Чүпрәледә үткәрелгән чаралар тур.] // Мәдәни җомга. – 2011. – 21 гыйнвар (№3). – Б. 4.

Кайту = Возвращение: Һади Атласиның тууына 135 ел: 2011 елның 12 гыйнварында Чүпрәле районында күренекле татар тарихчысы, галим, мәгърифәтче Һади Атласига багышлап үткәрелгән чаралар турында / төз. Г. Рәхим. – Казан: «Җыен» фонды: «ТАИФ» ААҖ, 2011. – 63 б.

В Дрожжановском районе установлена мемориальная доска Хади Атласи: [12.01.2011 г. в селе Нижнее Чекурское Дрожжановского района РТ сост. торжествен. митинг, посвящён. открытию мемориальной доски выдающемуся татар. обществен. и религиоз. деятелю,

учёному-историку Хади Атласи] // Время и Деньги. – 2011. – 13 января (№3). – С. 8.

**2012**

Асылов Д. Атласига тугрылык: [Бөгелмәдә күренекле-тарихчы галим Һади Атласига багышланган конференция узды] // Мәдәни җомга. – 2012. – 30 март (№13). – Б. 8.

Атласи – бөек шәхесләрдән: тарихчы-галим, мәгърифәтче, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Һади Мифтахетдин улы Атласов эшчәнлегенә багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары / ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы; Бөгелмә муниципаль р-ны Башкарма ком-ты; фәнни ред. Л.А.Гайфуллина; төз.: Ф.Т.Мәхмүтова, Р.С.Җәләев. – Бөгелмә, 2012. – 72 б.

Галләм Р. Атласи кайда туган?: [Һади Атласи шәҗәрәсе] // Мәгърифәт = Просвещение. – 2012. – 7 декабрь (№49). – Б. 3.

Галләм Р. Һади Атласи шәҗәрәсе: [Һади Атласи шәҗәрәсе тур.] // Мәдәни җомга. – 2012. – 23 ноябрь (№47). – Б. 14–15.

Галләм Р. Һади Атласиның нәсел дәрәҗәсе буенча яңа мәгълүматлар: [Һади Атласи шәҗәрәсе] // Шәһри Казан. – 2012. – 4 декабрь (№138). – Б. 6.

Гаффаров И. Атлас бабайның бөек варисы: [Һади Атласиның шәҗәрәсе тур.] // Мәдәни җомга. – 2012. – 3 август (№31). – Б. 14.

Заһидуллина Г. Җәрәхәтле заман баласы: [тарихчы, галим, репрессия корбаны Һ.Атласи тур.] // Мәгариф = Просвещение. – 2012. – №12. – Б. 88–89.

Хисмәтуллина Н. Һади Атласи – милләтебез горурлыгы: [дәрес] // Фән һәм мәктәп = Наука и школа. – 2012. – №2. – Б. 2–6.

Рәхмәтуллина Н. Ак байларга – ак өметләр: [Казанда Россия төбәкләрендә яшәүче татар эшкуарлары җыены булды] // Мәдәни җомга. – 2012. – 30 март (№13). – Б. 9.

**2013**

Таһиров И. Мирсәет Солтангалиев һәм Һади Атласи: [тарих] // Фән һәм тел = Наука и язык. – 2013. – №1–2. – Б. 54–57.

**2014**

Гафаров И. Тискәре нәтиҗә дә – нәтиҗә: [Һади Атласов шәҗәрәсенә кагылышлы фактлар тур.] // Мәдәни җомга. – 2014. – 18 июль (№28). – Б. 11.

**2016**

Бәйрәмова Ф. Атласиның милли-сәяси язмалары: [Һади Атласиның милләт темасына карата язылган хезмәтләре тур.] // Мәдәни җомга. – 2016. – 20 май (№19). – Б. 11; 3 июнь (№21). – Б. 18; 8 июль (№26). – Б. 16.

Бәйрәмова Ф. Соңгы туранчы...: [тарихчы-галим, җәмәгать эшлеклесе Һади Атласи тур. // Казан утлары. – 2016. – №8. – Б. 140–166; №10. – Б. 139–160; №11. – Б. 156–175.

Бәйрәмова Ф. Һади Атласи – татарның азатлык көрәшчесе: [күренекле җәмәгать эшлеклесе, милли азатлык көрәшчесе, танылган тарихчы, мәгърифәтче, язучы М.М.Атласиның тууына 140 ел тула] // Мәйдан. – 2016. – №8. – Б. 52–61.

Бәйрәмова Ф. Соңгы туранчы...: фәнни-популяр язма. – Казан: Аяз, 2016. – 134 б.

Гафаров И. Һади Атласи турында яңа чыганаклар // Безнең мирас. – 2016. – №8. – Б. 6–12.

Мөхәммәтша Р. Һади Атласи (1876–1938): [тарихчы, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Һ.Атласиның соңгы еллардагы тормышы тур.] // Безнең мирас. – 2016. – №12. – Б. 88–89.

Шакуров Ф.Н. Этногенетические концепции татарских историков конца XIX–начала XX века: [о трудах Ш.Марджани, Р.Фахретдина, Х.Габяши, Г.Ахмарова, А.Валиди, Х.Атласи] // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. – 2016. – №6. – С. 368–379.

**2018**

Абзалова-Сәлманова Р. Чын тамырлар – Мәккә-Мәдинәдә!: [милләтнең бик күп мәшһүр шәхесләренең (Риза Фәхретдин, Һади Атласи һ.б.) тормыш юлы Лениногорск районындагы бай тарихлы Чыршылы авылы б-н бәйләнгән] // Мәдәни җомга. – 2018. – 12 гыйнвар (№1). – Б. 16–17; 19 гыйнвар (№2). – Б. 16; 26 гыйнвар (№3). – Б. 16; 2 февраль (№4). – Б. 16; 9 февраль (№5). – Б. 15.

**2019**

Байрамова Ф. Первая тюрьма Атласи: [татарский общественный деятель, историк] // Звезда Поволжья. – 2019. – 24–30 октября (№38); 31 октября–6 ноября (№39); 7–13 ноября (№40); 14–20 ноября (№41).

Байрамова Ф. Последний туранец Атласи...: [Хади Атласи – общественный деятель, депутат Государственной думы Российской империи II созыва от Самарской губернии, историк-тюрколог, педагог] // Звезда Поволжья. – 2019. – 12–18 сентября (№32).

Габдрафикова Л.Р. Хади Атласи и Фазыл Туйкин глазами бугульминской молодёжи // Татарские селения Юго-Восточного Закамья: очаги просвещения и культуры: [коллективная монография] / Х.Х.Багаутдинова, О.О. Владимиров, Л.Р. Габдрафикова [и др.]; отв. ред. А.И. Ногманов; Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2019. – С. 226–232.

**2020**

Бәйрәмова Ф. Соңгы туранчы...: [ТАССР төзелүгә 100 ел; тарихчы, җәмәгать эшлеклесе Һади Атласи тур.] // Мәдәни җомга. – 2020. – 19 июнь (№24). – Б. 11.

**2021**

Заһидуллин И. Татар патриоты – Һади Атласи: [дин һәм җәмәгать эшлеклесе, репрессия корбаны Һади Атласи тур. ] // Татарстан. – 2021. – №10. – Б. 70–73.

**2022**

Байсарлы В. Бөгелмәдә милли тантана: [тарихчы, җәмәгать эшлеклесе Һади Атласины Бөгелмәдә зурладылар] // Мәдәни җомга. – 2022. – 11 март (№9). – Б. 12–13.

Хәбипова З. «Белем – оҗмахның баскычыдыр»: [күренекле тарихчы-галим, җәмәгать эшлеклесе Һади Атласи тур.] // Татарстан яшьләре. – 2022. – 5 май (№17). – Б. 14.

Шакиров А. Хади Атласи. Политик, историк, богослов: [Хади Атласи – общественный деятель, депутат Государственной думы

Российской империи II созыва от Самарской губернии, историк-тюрколог, педагог] // Татарстан. – 2022. – №10. – С. 76–79.

**2024**

Аймалетдин Х. Һади Атласи – милли мәгърифәтче: [мәгърифәтче Һади Атласи турында] / Хөсәен Аймалетдин, Фәүзия Бәйрәмова-Аймал // Туган җир = Родной край. – 2024. – №3. – Б. 152–158.

Бәйрәмова Ф. Һади Атласи – милли мәгърифәтче // Мәдәни җомга. – 2024. – 3 май (№17). – Б. 5.

Вәлиәхмәт Ф. Туган ягым – Карабашым: [Бөгелмә районындагы Карабаш бистәсенә – 360 ел, Һади Атласи музей-китапханәсенә 20 ел] // Бөгелмә авазы. – 2024. – 15 ноябрь (№45). – Б. 4.

**2025**

Мөхәммәтшин З. Һади Атласи – Чүпрәленең бөек шәхесе // Безнең мирас. – 2025. – №11. – Б. 29–33.

**2026**

Олуг фикер иясе истәлегенә // Мәдәни җомга. – 2026. – 6 февраль (№4). – Б. 4.

КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** | **БОЕРЫК**

2025 ел, 1 июль г.Казань № б-1463

Тарихчы, педагог, җәмәгать эшлеклесе Һади Атласиның (Мөхәммәдһади Мифтахетдин улы Атласовның) тууына 150 ел тулачак уңаеннан:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районындагы җирле үзидарә органнарының 2026 елда Татарстан Республикасында Һади Атласиның 150 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган чаралар уздыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Һади Атласиның 150 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетын төзергә.

3. Түбәндәгеләрне (боерыкка теркәләләр) расларга:

Һади Атласиның 150 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составын;

Һади Атласиның 150 еллыгын бәйрәм итү буенча төп чаралар планын.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында Һади Атласиның 150 еллыгын бәйрәм итүне киң яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

**Эчтәлек**

Кереш сүз .................................................................................................. 3

Һади Атласи исемендәге «Мәгърифәтче»-
«Просветитель» премиясе лауреатлары исемлеге) ............................... 6

Соңгы туранчы *(Һади Атласины искә алу кичәсе)* ............................... 9

Викторина үткәрү өчен сораулар ..........................................................11

Һади Атласи турында кызыклы 10 факт .............................................. 14

Библиография ....................................................................................... 18

Басарга кул куелды 05.06.2026. Форматы 60x84 1/16.
Тиражы 75 данә. Заказ № 513.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе,
«Милли китап» нәшрияты.
420015, Казан шәһәре, Пушкин ур., 86 йорт.

Подписано в печать 05.06.2026. Формат 60x84 1/16.
Тираж 75 экз. Заказ № 513.
Национальная библиотека Республики Татарстан,
Издательство «Милли китап».
420015, г. Казань, ул. Пушкина, д. 86.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият бүлегендә басылды.
420015, Казан шәһәре, К.Маркс ур., 36 йорт.

Отпечатано в редакционно-издательском отделе
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420015, г. Казань, ул. К.Маркса, 36.

